**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 30 гыйнварындагы 275 номерлы карары**

# Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында «Родина урамыннан һәм Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карары, Татарстан республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча расланa торган очракларны билгеләү турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 27 апрелендәге 1690 номерлы «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында «Родина урамыннан Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гыкарары, «Анжелика Мелентьеваның проект артеле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында «Родина урамыннан һәм Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең борылыш нокталары координаталары исемлегеннән, территорияне ызанлау проекты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (1 нче этап), 1 нче этапта үзгәртелә торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (2 нче этап) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 30 гыйнварындагы
275 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында «Родина урамыннан һәм Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты**

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында «Родина урамыннан һәм Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Кызыл линияләр сызымы, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының сызымы.

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән урнаштыру турындагы нигезләмәдән.

III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).

IV. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).

V. Территорияне ызанлау проекты. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре (1 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре (2 нче этап) чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән текстлы өлеше.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләрнең борылыш нокталары координаталары исемлеге, территорияне ызанлау проекты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (1 нче этап),

1 нче этапта үзгәртелә торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (2 нче этап) хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Кызыл линияләр сызымы, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре, урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының сызымы.



## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

### Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектының, шулай ук урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының исеме, төп характеристикалары һәм билгеләнеше

Объектның исеме: «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында Родина урамыннан һәм Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап»

Объектның билгеләнеше: район әһәмиятендәге магистраль урам.

### Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектының төп характеристикалары

| № т/б | Сыйфатламасы | Күрсәткеч |
|---|---|---|
| 1 | Категориясе | Район әһәмиятендәге урам |
| 2 | Трассаның озынлыгы, км | 0,5 |
| 3 | Хәрәкәт полосасы киңлеге, м | 3,75 |
| 4 | Хәрәкәт полосалары саны, данә | 4 |
| 5 | Хәрәкәтнең исәп тизлеге, км/сәг | 60 |
| 6 | Кызыл линияләрдәге урам киңлеге, м | 40 |
| 7 | Автомобиль юлының киңлеге, м | 16,0 |
| 8 | Тротуарларның киңлеге, м | 3,0 |

Родина урамы, Нәҗип Җиһанов урамы – автомобиль юллары белән кисешү бер дәрәҗәдә, көйләнә итеп каралган.

Юллар киселешендә җәяүлеләр өчен куркынычсыз кичүләр оештыру, җайга салу чаралары һәм махсус техник җиһазлар урнаштыру күздә тотыла.

Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектының составында түбәндәгеләр каралган:

- машина йөрү өлешен, тротуарларны, велосипед йөрү юлын, инженерлык челтәрләренең техник коридорларын үз эченә алган урам-юл челтәрен төзекләндерү;
- инженерлык коммуникацияләре салу (яктырту линиясе 0,4 кВ, яңгыр канализациясе);
- гамәлдәге инженерлык челтәрләрен үзгәртеп кору.

Линия объектын план буенча урнаштыру чикләре урамның билгеләнгән кызыл линияләренә туры килә.

**Территорияләрендә линия объектын план буенча урнаштыру зонасы билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге җирлекләр, торак пунктлар, шәһәр эчендәге территорияләр исемлеге**

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районы чикләрендә билгеләнә.

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары**

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә төзелеш каралмаган.

Линия объектының инженерлык челтәрләре коридорларында инженерлык белән тәэмин итү челтәрләрен урнаштыру планлаштырыла. Инженерлык челтәрләрен урнаштыруның җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенешләре урнаштырыла торган инженерлык челтәрләренең сак зоналары күләмнәре белән билгеләнә.

**Территорияне планлаштыру проектын әзерләгәндә һәм ызанлау вакытына гамәлдәге һәм төзелә торган, саклана торган капиталь төзелеш объектларын, шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзергә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын күрү зарурлыгы турында мәгълүмат**

Территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү вакытына линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә урнашкан гамәлдәге инженерлык челтәрләре реконструкцияләнергә тиеш: урнаштыру планлаштырыла торган урамны инженерлык челтәрләре коридорларына күчерү,

урамны саклау чаралары белән киселешен җайлау (үткәргеч торбаларны футлярларга яңадан урнаштыру, һава электр тапшыру линияләрен кабель линияләренә үзгәртеп кору).

## Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Планлаштыру һәм ызанлау проекты чикләрендәге территориядә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) Бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары юк. Планлаштыру һәм ызанлау проекты территориясе мәдәни мирас объектларын саклау зоналарыннан читтә урнашкан.

Проектлау территориясендә ачыкланган мәдәни мирас объектларының я мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларның булмавы турында белешмәләр юк.

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль закон таләпләренә нигезендә, линия объекты территориясендә түбәндәгеләрне башкару кирәк:

- 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль законның 45.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә археологик тикшерүләр юлы белән җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләр йогынтысына дучар ителергә тиешле җир кишәрлегенә тарихи-мәдәни экспертиза үткәрүне һәм финанслауны тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетына җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләр йогынтысына дучар булган җир кишәрлегендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларның булуы яисә булмавы билгеләнә торган тикшеренү нәтиҗәләрен үз эченә алган документацияне, шулай ук күрсәтелгән документациягә (я җир кишәрлегенә) дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен тапшырырга.

Карап тикшерелә торган территориядә археологик мирас объектлары, шулай ук мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар табылган очракта, түбәндәгеләрне башкару кирәк:

- проект документациясе составында ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында яисә кырда башкарыла торган

археологик коткару эшләрен уздыру турында бүлекне я ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектын яисә уздырыла торган эшләрнең күрсәтелгән мәдәни мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру планын эшләргә;

- ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү чараларын нигезли торган документлар яисә документлар бүлеге буенча дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен алырга һәм аны күрсәтелгән документлар белән бергә килештерү өчен Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетына тапшырырга;

- ачыкланган мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү чараларын нигезли торган килештерелгән документациядә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Объектны төзегәндә һәм аннан файдаланганда әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә гамәлдәге норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Объект төзелеше барышында әйләнә-тирә мохитне пычранудан саклау максатыннан түбәндәге чаралар тәкъдим ителә, аларны гамәлгә ашыру табигать мохитенә тискәре йогынтыны булдырмый калырга яисә максималь киметергә мөмкинлек бирәчәк:

- эшләрне проект белән билгеләнгән җир кишәрлеген бирү чикләрендә генә башкару;

- эшләр башкару барышында барлыкка килә торган җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, сортларга аеру, вакытлыча саклау системасын оештыру, агып төшә торган суны туфракка кертүне булдырмый торган махсус җиһазландырылган мәйданчыкларда;

- куркынычлык классына туры китереп, барлыкка килгән калдыкларны якындагы каты коммуналь калдыклар полигонына чыгару;

- пычраткыч матдәләр чыгару буенча норматив таләпләр нигезендә транспорт чараларының һәм төзелеш техникасының техник торышын тоту, пычраткыч матдәләрне эшләүче машиналардан чыгаруны вакыт-вакыт контрольдә тоту; машиналарга һәм механизмнарга техник хезмәт күрсәтү, юу

һәм аларны тутыру, пычранган суларны туфрак мохитенә эләкмичә утильләштерүне күздә тота торган махсус җиһазландырылган мәйданчыкларда ГСМ саклау;

- билгеләнгән конструкцияләрнең булуын яки зарарлануларының булмавын билгеләү һәм авария хәлләре килеп чыгуны кисәтү максатында эшләр участогын даими карау;

- күчереп төяү яисә төяү эшләрен башкарганда туфракны су сибеп тузансызландыру.

Объектны файдалану чорында әйләнә-тирә мохитне йогынтыдан саклау максатыннан түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

- транспорт чараларының техник торышын пычрату матдәләре чыгару норматив таләпләре нигезендә тоту;

- юл өслеге итеп аз тавышлы һәм аз тузан чыгара торган асфальтны куллану;

- өслектәге су агынтыларын җыю һәм чыгару максатыннан яңгыр канализациясен оештыру.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Проектлана торган корылмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне булдырмау өчен проектта түбәндәгеләр каралган:


- технологик җиһазларны, шартлау куркынычы категориясен исәпкә алып, нормалар буенча кирәкле юлларны тәэмин итеп һәм кирәк булган янгынга каршы өзеклекләрне исәпкә алып урнаштыру;

- объектны файдалануга тапшыру алдыннан янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы кешеләр билгеләнә;


- төзелеш эшләре вакытында ягулык-майлау материалларының агып төшүен булдырмау кирәк.

Линия объектын эксплуатацияләү чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары нигездә махсуслаштырылган бригадаларның торышын даими тикшереп торуны оештырудан, техник хезмәт күрсәтүне һәм планлы ремонт эшләрен башкарудан гыйбарәт.

## III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).



# IV. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).



## V. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше

Линия объекты территориясен ызанлау проекты Казан шәһәренең Совет районында «Родина урамыннан һәм Рихард Зорге урамына кадәр юл, Родина урамнары арасындагы участок, 1 этап» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты составында әзерләнде.

Планлаштыру структурасы элементы чикләрендә гомуми файдаланудагы җир кишәрлеге ясау максатыннан кадастр эшләрен ике этапта уздыру таләп ителә.

ызанлауның 1 нче этабы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- үзгәртелгән чикләрдә кадастр номерлары 16:50:060202:14, 16:50:060202:5, 16:50:060202:234, 16:50:060202:214, 16:50:060202:26, 16:50:060202:236, 16:50:060202:235, 16:50:060202:237, 16:50:060310:233, 16:50:000000:26708 булган җир кишәрлекләрен саклап калып бүлү;
- дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән өч җир кишәрлеге төзү;
- 16:50:060202:459 кадастр номерлы җир кишәрлеген чикләнмәгән дәүләт милке җирләре белән яңадан бүлү.

Кадастр номер 16:50:000000:26708 булган җир кишәрлеген саклап калып бүлүне әлеге җир кишәрлегенең 13 нче контуры чикләре буенча башкарырга тәкъдим ителә.

1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре турында белешмәләр, шул исәптән ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы һәм аларны ясалануының мөмкин булган ысуллары турында белешмәләр 1 нче таблицада бирелгән.

1 нче таблица

**1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре**

| **Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Мөмкин булган ясау ысулы** | **Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 16:50:060202:14 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 1350 |
| :ЗУ2 | 16:50:060202:5 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 430 |
| :ЗУ3 | 16:50:060202:234 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 1811 |
| :ЗУ4 | 16:50:060202:214 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 422 |
| :ЗУ5 | 16:50:060202:26 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән | 230 |

| Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе | Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мөмкин булган ясау ысулы | Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|
| | | чикләрдә саклап калып, бүлү | |
| :ЗУ6 | 16:50:060202:236 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 163 |
| :ЗУ7 | 16:50:060202:235 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 826 |
| :ЗУ8 | 16:50:060202:237 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 44 |
| :ЗУ9 | 16:50:060310:233 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 395 |
| :ЗУ10 | 16:50:000000:26708 | Җир кишәрлеген үзгәртелгән чикләрдә саклап калып, бүлү | 1 |
| :ЗУ11 | - | дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлеге төзү | 3902 |
| :ЗУ12 | - | дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлеге төзү | 1465 |
| :ЗУ13 | - | дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән җир кишәрлеге төзү | 3564 |
| :ЗУ14 | 16:50:060202:459 | Дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән җир кишәрлеген яңадан бүлү | 7278 |

Бүлгәндә үзгәртелгән чикләрдә саклanучы җир кишәрлекләре турында белешмәләр, 2 нче таблицада күрсәтелгән.

2 нче таблица

**Үзгәртелгән чикләрдә 1 нче этапта сакланучы җир кишәрлекләре**

| Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Үзгәртелгән чикләрдә җир кишәрлегенең мәйданы, кв. м |
|---|---|
| 16:50:060202:14 | 6256 |
| 16:50:060202:5 | 209 |
| 16:50:060202:234 | 848 |
| 16:50:060202:214 | 616 |
| 16:50:060202:26 | 438 |
| 16:50:060202:236 | 4390 |
| 16:50:060202:235 | 142 |
| 16:50:060202:237 | 505 |
| 16:50:060310:233 | 4353 |
| 16:50:000000:26708 | 12 |

2 нче этап 1 нче этапта 16:50:060202:461, 16:50:060310:2, 16:50:000000:34202 кадастр номерлары белән җир кишәрлекләреннән ясалган җир кишәрлекләрен берләштерүне үз эченә ала.

2 нче этапта кадастр эшләрен 1 нче этапта кадастр эшләрен уздырганнан соң, шул исәптән хосусый милектәге җир кишәрлекләрен (җир кишәрлекләренең өлешләрен) мәҗбүри алу һәм әлеге җир кишәрлекләренә муниципаль милек хокукын теркәү, шулай ук әлеге җир кишәрлекләренә рөхсәт ителгән файдалануның «Урам-юл челтәре» төре бирелгәннән соң башкарырга кирәк (код 12.0.1, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы әмере) рөхсәт ителгән куллану төрен бирү.

2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре турында белешмәләр, шул исәптән ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы һәм аларны ясалануның мөмкин булган ысуллары турында белешмәләр 3 нче таблицада бирелгән.

3 таблица

**2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләре**

| **Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры/шартлы билгеләнеше** | **Мөмкин булган ясау ысулы** | **Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ15 | 16:50:060202:461, 16:50:060310:2, 16:50:000000:34202, :ЗУ1, :ЗУ2, :ЗУ3, :ЗУ4, :ЗУ5, :ЗУ6, :ЗУ7, :ЗУ8, :ЗУ9, :ЗУ10, :ЗУ11, :ЗУ12, :ЗУ13, :ЗУ14 | Җир кишәрлекләрен берләштерү | 22420 |

Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге һәм аларның мәйданы турында белешмәләр 4 нче таблицада бирелгән.

4 таблица

**Гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләре**

| Ясала торган җир кишәрлегенең шартлы билгесе | Этап | Җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| :ЗУ1 | 1 | 1350 |
| :ЗУ2 | 1 | 430 |
| :ЗУ3 | 1 | 1811 |
| :ЗУ4 | 1 | 422 |
| :ЗУ5 | 1 | 230 |
| :ЗУ6 | 1 | 163 |
| :ЗУ7 | 1 | 826 |
| :ЗУ8 | 1 | 44 |
| :ЗУ9 | 1 | 395 |
| :ЗУ10 | 1 | 1 |
| :ЗУ11 | 1 | 3902 |
| :ЗУ12 | 1 | 1465 |
| :ЗУ13 | 1 | 3564 |
| :ЗУ14 | 1 | 7278 |
| :ЗУ15 | 2 | 22420 |

Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) мәҗбүри алу күздә тотыла торган җир кишәрлекләре исемлеге 5 нче таблицада бирелгән. Санап үтелгән җир кишәрлекләре (җир кишәрлекләренең өлешләре) бер-берсеннән бәйсез рәвештә мәҗбүри алынырга мөмкин.

Мәҗбүри алу шулай ук мәҗбүри алынырга тиешле җир кишәрлекләрендә (җир кишәрлекләренең өлешләрендә) урнашкан барлык күчемсез мөлкәт объектларына карата да күздә тотыла, моңа дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрендә урнаштыру мәҗбүри алу максатына каршы килми торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) керми.

5 таблица

**Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) мәҗбүри алу күздә тотыла торган гамәлдәге җир кишәрлекләре**

| **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Мәҗбүри алу/резервлау** | **Беренчел җир кишәрлегенең мәҗбүри алына торган өлешенең шартлы билгеләнеше** |
|---|---|---|
| 16:50:060202:14 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ1 |
| 16:50:060202:5 | Җир кишәрлегенең бер өлешен резервлау | :ЗУ2 |
| 16:50:060202:234 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ3 |
| 16:50:060202:214 | - | :ЗУ4 |
| 16:50:060202:26 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ5 |
| 16:50:060202:236 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ6 |
| 16:50:060202:235 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ7 |
| 16:50:060202:237 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ8 |
| 16:50:060310:233 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ9 |
| 16:50:000000:26708 | Җир кишәрлегенең бер өлешен мәҗбүри алу | :ЗУ10 |
| 16:50:060202:459 | Җир кишәрлеген мәҗбүри алу | |
| 16:50:060202:461 | Җир кишәрлеген мәҗбүри алу | |
| 16:50:060310:2 | - | |
| 16:50:000000:34202 | Җир кишәрлеген резервлау | |

Искәрмә.
«-» билгесе җир кишәрлегенә хокук ияләре турында мәгълүмат Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында юк дигәнне аңлата. Әлеге җир кишәрлекләре өчен процедура тибы (мәҗбүри алу яки резервлау) тиешле җир кишәрлегенең хокук иясе турында мәгълүматлар ачыкланганнан соң билгеләнәчәк һәм әлеге проектка үзгәрешләр кертүне таләп итми.